**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет
Азнакаевского
муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы
башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево,
423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай
шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«__17_» ____10___ 2023 ел.** **№ __262___**

2023 елның IV кварталына Азнакай муниципаль районы буенча торакның бер квадрат метры бәясенең нормативын билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 октябрендәге 1050 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын арзан һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында, «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр союзы» коммерцияле булмаган партнерлыгын Азнакай шәһәрендә торак урыннарының бер квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшерү нәтиҗәләрен исәпкә алып, Азнакай муниципаль районында «Бәяләр диапазонын билгеләү турында»гы 2023 елның 20 августындагы 233 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 карары белән расланган “Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында торак сатып алуга яшь гаиләләргә социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты нигезендә, карар бирә:

1. Яшь гаиләләргә торак урыннар сатып алуга социаль түләү күләмен исәпләү өчен Азнакай муниципаль районы буенча торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясенең нормативын 39 683 (утыз тугыз мең алты йөз сиксән өч) сум күләмендә билгеләргә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы,
икътисад һәм финанслар буенча җитәкче урынбасары О.Н. Газизова